| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2020 г.Зеленодольск № 38

Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар торган, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында

Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар торган, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дёгтева мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 ст. нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар торган, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы

шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен, 1 нче кушымтада каралганчы, расларга.

2. Әлеге карар нигезләмәләре бюджетларның 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорыннан башлап, бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль**
**районы Башлыгы ,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

1 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы Советы Карары буенча
№ 38, 2020 елның 29 декабре

Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар торган, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар торган, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар, оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлардан торган, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

4. Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

5. Башка бюджетара трансфертларны бирү шарты булып түбәндәгеләр тора:

а) җирлек бюджетында (җирлек бюджетының җыелма бюджет язмасында) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү

максатларында җирлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуы ;

б) җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бирүнең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган төп шартларын үтәве.

6. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетларына күчерелә.

7. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар, Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килгән елның 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар акчаларының калган өлешен, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

9. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

10. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары закон нигезендә контрольдә тота.